**Милли бизәк**

1) Өебезнең түрендә
Утыра серле сандык.
Ул сандыкта сакланадыр
Тау кадәре зур байлык.

Чиккән сөлге, затлы яулык,
Бизәктән күз камаша.
Милли киемнәрне киеп
Күрсәтикче тамаша!

Кушымта:
Яулык, күлмәк, чулпы, читек – апама!
Энемә – түбәтәй, камзул һәм чалбар!
Хәситә, алка, беләзек – сеңлемә.
Ак калфагым бик килешә йөземә!

2) Әбиемнең сандыгында
Халкымның бай мирасы.
Кадерләп саклыйк, туганнар,
Ул – безнең күз карасы.

Затлы хәзинә саргаеп
Ятмасын ла сандыкта,
Татар милли бизәкләре
Яшәсен һәрбер йортта.